КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2018 ел, 26 декабрь | г.Казань | № 1232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карар белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 16 февраль, 59 нчы; 2006 ел, 7 июнь, 282 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 858 нче; 2009 ел, 24 февраль, 98 нче; 2010 ел, 31 март, 205 нче; 2011 ел, 10 июнь, 470 нче; 2011 ел, 13 август, 673 нче; 2012 ел, 17 август, 716 нчы; 2013 ел, 7 март, 153 нче; 2013 ел, 25 ноябрь, 924 нче; 2014 ел, 7 июнь, 387 нче; 2015 ел, 27 ноябрь, 897 нче; 2016 ел, 8 апрель, 202 нче; 2016 ел, 3 август, 531 нче; 2016 ел, 24 ноябрь, 873 нче; 2017 ел, 4 июль, 459 нчы; 2017 ел, 15 ноябрь, 876 нчы; 2017 ел, 27 декабрь, 1052 нче; 2018 ел, 11 июнь, 456 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты турындагы нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«Комитет үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлекләрен тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин